Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының “Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе



# *Гайфуллина Гөлнур Ибраһим кызы, ветеран-педагог, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Гайфуллина Гөлнур Ибраһим кызы 1956 нчы ел 4 ноябрендә Чистай районы Татарская Волчья авылында (хәзерге Яңа Чишмә районы Акбүре авылы) туа. Үз авылларында сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, күрше Аксубай районы Яңа Ибрай авылында урта мәктәптә белем ала. Казан дәүләт университеты татар теле филологиясе факультетына читтән торып укырга керә. Иң беренче педагогик хезмәт юлын Утяшкино авылында башлап җибәрә. "Мәктәп бусагасын беренче кат атлап эшкә килгәндә, чит кеше балаларының ап-ак кәгазьдәй күңеленә җир йөзендә булган иң-иң яхшы сыйфатларны гына салырга тиешлегемне тулысы белән аңлап та бетермәгәнмендер әле мин. Үзем башкарган эшнең никадәр җаваплылык таләп итүен еллар үткән саен төшенә генә бардым", - дип искә ала ул елларны Гөлнур Ибраһим кызы.

1980 нче елда Түбән Кама шәһәренә күчеп килгәннән соң, балалар бакчасында тәрбияче, 4 нче урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 1989 нчы елда яңа ачылган 27 нче урта мәктәптә үзенең педагогик хезмәтен дәвам итә. 29 ел буе шушы мәктәптә укучыларга татар теле һәм әдәбияты укыта. Ул бар көчен, иҗади сәләтен милли мәгарифне үстерүгә юнәлтә, белем һәм тәрбия бирүнең эчтәлеген яңарту юнәлешендә нәтиҗәле эшли. Укытучы яңа алымнар ярдәмендә укучыларны мөстәкыйль эшчәнлеккә җәлеп итә, укучыларда туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, ата-анага, өлкәннәргә карата шәфкатьлелек хисләре тәрбияли. Аның тырыш хезмәте күп санлы Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары һәм дипломнар белән бәяләнгән:

-Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль берәмлеге башлыгының Мактау грамоталары, 1997, 2014 нче еллар;

-Түбән Кама шәһәре мәгариф идарәсенең Рәхмәт хаты, 1994, 1995 нче еллар;

-Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама районы хакимиятенең халык депутатлары берләшкән Советының Мактау грамотасы, 1997 нче ел;

-27 нче мәктәп администрациясенең Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары, 2009, 2011, 2014 нче еллар.

Бүгенге көндә Гөлнур Ибраһим кызы лаелы ялда. Тормыш иптәше Фаил белән бер малай һәм бер кыз тәрбияләп үстергәннәр. Хәзерге көндә алты оныгының яраткан дәү әнисе. Милли тәрбия бирүдә дәү әниләренең роле бик зур. Оныкларының тәртипле, әхлаклы, зиһенле, тәүфикълы, шәфкатьле булып тәрбияләүдә зур ярдәм итә.

Гөлнур Ибраһим кызы - 27 нче мәктәптә оештырылган чараларда актив катнашучы. Һәр елда Бөтендөнья "Татарча диктант" акциясендә, Өлкәннәр көне уңаеннан уздырылган кичәләрдә актив катнаша.



МАКТАУ ГРАМОТАСЫ
БЕЛӘН БҮЛӘКЛИ



НИЖНЕКАМСКОГО РАЙОНА

НАГРАЖДАЮТ
ПОЧЕТНОЙ ГРАМОТОЙ



НАГРАЖДАЕТСЯ
ПОЧЕТНОЙ ГРАМОТОЙ



Благодарственное письмо

Уважаемая
Гульнур Ибрагимовна!



Уважаемая
Гульнур Ибрагимовна!



Награждается
в связи с 20-летием
МОУ «Средняя общеобразовательная школа №27
с углубленным изучением отдельных предметов»

Гайфуллина
Гульнур Ибрагимовна,

учитель татарского языка и литературы,
за плодотворный добросовестный труд
на благо родной школы со дня её основания.

Директор школы — Л.В.Ярцева

Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары



Коллегалар  белән. 1 нче сентябрь



“Татарча диктант” акциясе. 2023 нче ел



52 елдан соң класстлашлар белән очрашу. 2023 нче ел



Туган көндә балалар, кияү, килен, оныклар белән. 4 нче ноябрь 2022 нче ел